# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай район Советы

Азнакай шәһәре № 206-30 «22» август 2018 ел

«Азнакай муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең җирле үзидарә органнары
тарафыннан Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районының 2010 елның 15 декабрендәге
24-5 номерлы карары белән расланган муниципаль
бюджет учреждениесе функцияләрен һәм
вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы Нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

Хокук нигезләренә яраклаштыру максатыннан Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар чыгарды:**

1. «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2010 елның 15 декабрендәге 24-5 номерлы карары белән расланган муниципаль бюджет учреждениесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 2 пунктның «в» пунктчасын киләсе редакциядә бәян итәргә:
«в) муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесен билгеләү (раслау) белән килешә һәм аның вәкаләтләрен туктата;
1.2. 2 пунктның «г» пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2010 елның 15 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны рәис урынбасары Н.М.Нәгыймовка йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин